СОВЕТ
НИЖНЕЧЕКУРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН ЧӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Нижнее Чекурское

**15 май 2020 ел** **№ 60/4**

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Түбән Чәке авыл
җирлеге депутаты статусы турында
нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон (2019 елның 16 декабренә үзгәрешләр белән) нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының 05.11.2019 № 53/1 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Түбән Чәке авыл җирлеге советы депутатының статусы турында нигезләмәгә, 16 статьясындагы 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Авыл җирлеге вәкиллекле органы депутатын муниципаль вазыйфа биләүгә дәгъва кылучы зат үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына белешмәләр тапшыра. Авыл җирлеге вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими булмаган нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат әлеге белешмәләрне депутат булып сайланган, вакантлы депутат мандатын аңа тапшырган яисә даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны туктаткан көннән алып дүрт ай эчендә, шулай ук белешмәләр (хисап чоры) тапшыру елыннан алдагы һәр ел эчендә, Федераль законның 3 декабрендәге 20 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләрнең хисап чоры дәвамында башкарылган очракта, тапшыра.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең рәсми сайтында рәсми басылып чыккан мизгеленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Түбән Чәке
авыл җирлеге башлыгы: О. Б. Албутов